**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав., 423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

____________ №____

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актаныш каты көнкүреш калдыклары полигоны» муниципаль унитар предприятиесен хосусыйлаштыруга әзерлек турында**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2023 елның 15 декабрендәге 33-04 номерлы карары белән расланган, 2024 елга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фаразлау планы (программасы) нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актаныш каты көнкүреш калдыклары полигоны» муниципаль унитар предприятиесе директоры (алга таба - Предприятие) Сәетгалиев Марат Әбелгали улына предприятиене җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә үзгәртеп кору юлы белән хосусыйлаштыруга әзерләү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруны йөкләргә:

1.1. Предприятиенең мөлкәтен һәм йөкләмәләрен 2024 елның 15 мартына инвентаризацияләргә;

1.2. Арадаш бухгалтерлык балансы һәм аның аудитын төзүне Предприятиянең мөлкәтен һәм йөкләмәләрен инвентаризацияләү датасына тәэмин итәргә;

1.3. Арадаш баланс төзү датасына хосусыйлаштырылырга тиешле предприятие активларының составын һәм баланс бәясен билгеләргә;

1.4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгының 2002 елның 17 маендагы 179 номерлы карары белән расланган хосусыйлаштыруның бер типтагы планына 1 нче кушымтада күрсәтелгән документларны әзерләргә һәм хосусыйлаштыруга әзерлек өчен башка чаралар үткәрергә.

2. Саетгалиев Марат Әбелгали улына, 2024 елның 1 маена кадәр, билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хосусыйлаштыру планын, предприятиенең мөлкәтенә, хокукларына һәм йөкләмәләренә тапшыру актын, шулай ук җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять уставы проектын Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына раслауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы И.Ш.Бариевка йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 621DCE305601C88D15496913AD135909
Владелец: Ильясов Рустем Алмазович
Действителен с 10.04.2023 до 03.07.2024

**Таныштым:**

МУП "Актаныш ТБО полигоны"директоры ______________________/М.Ә.Сәетгалиев/